КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯДЕГӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

«09» июнь 2021 ел №12

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Янил авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Советы:

К А Р А Р  Б И Р Д Е :

1«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Ядегәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Ядегәр авыл җирлеге Советының .2014 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карары(Ядегәр авыл җирлеге Советының 16.12.2016 ел, №35, 21.06.2018 ел, №16, 2019 ел, №3 карары белән расланган» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге «муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре «нә үзгәрешләр кертү, 2019 елның 28 августындагы 14 номерлы) 18.1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«18. 1. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлегенең максималь күләме – 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы А.Н.Фәйзуллин